# Тарих эзләреннән...



Октябрь инкыйлабына кадәр һәм 1927 нче елларгача, халыкны рухи яктан бердәм итү өчен, мөселман дине тарафдарлары күп тырышлык куйганнар. Һәр татар авылындагы мәчет, аның күккә ашкан манарасы, ул манарадан бөтен авылга таралган азан тавышлары халкыбызның күңел кылларын тибрәткән, аны гомеренең соңгы көненә кадәр озата барган. Татар теленә, аның җырларына, гореф-гадәтләренә булган олы ихтирам хисләрен тәрбияләүдә мәчетләрнең роле әйтеп бетергесез зур булган. Авыл халкына Низаметдин мулла тоткан бер мәдрәсә һәм мәчет хезмәт иткән. Мәдрәсәгә шәкертләр тирә-як авыллардан да килеп укыганнар. Аның мөгаллимнәре Фазлый һәм Миргаяз мулла кебек шактый гыйлемле кешеләр булганнар. Дин укытуны мәчеттә Хисаметдинов Низаметдин мулла, аның кияве Разыев Шәрифҗан,соңрак Низаметдин мулланың улы Низамов Мирсәет мулла һәм хәлфәләр башкарган. Мәктәп чыгымнары балаларның үз өсләрендә булган. Мәдрәсәдә укучылар пәнҗешәмбе көнне кичләрен муллага һәм хәлфәгә 2-5 тиен күләмендә хәер биргәннәр. Ярлы крестьян балалары, түләрлек мөмкинлекләре булмау сәбәпле, укырга керә алмаганнар.

Мин белгәндә инде, мәдрәсә җитәкчесе Низаметдин мулла юк иде. Аның остазбикәсе Зәйнәп абыстайны, Мирсәет мулланы һәм аның гаиләсен генә хәтерлим. 1930 нчы елның җәендә безнең авыл мәчетенең дә манарасын төшерергә килделәр. Аны оештыручылар кемнәр булгандыр, анысын хәтерләмим. Ләкин мәчет манарасын кисеп аударуда авыл җәмәгатьчелеге катнашмады. Аны башкаручылар – рус авылыннан ялланган кешеләр, диделәр. Ул вакыйганы тамаша кылырга килүчеләр 30 кешедән артык булмагандыр. Мин үзем дә ул тирәдә ник чуалганыма үкендем: әти-әнидән бик нык эләккәне генә истә калган. 1931 нче елда Мирсәет мулланы, бай кеше исәбендә йөргән Мирзанны, авылдан сөрделәр. Ул соңгы көннәренә кадәр Удмуртия Республикасының  Воткинск шәһәрендә яшәде.

1920 нче елларда Күбәк авылында да тамырдан борылыш була. Комсомол, партия оешмалары барлыкка килә. Башлангыч мәктәп ачыла. Элгәре ул бер крестьян йортында эшли башлый. Авыл крестьян балалары шунда йореп белем ала. Беренче укытучылар Үтәев Бикмулла һәм Кадыйров Әмирҗан булганнар. Еллар үту белән, 1926-1927 нче елларда дәүләт ярдәмендә ике сыйныф бүлмәле мәктәп салдырыла. Әмәкәйдә зур тегермән тоткан Латыйп байның кара-каршы итеп төзелгән зур йортын авылның көньяк-көнчыгышындагы буш яланга мәктәп бинасы итеп кучерәләр. Уку гарәп алфавиты нигезендә алып барылган. Анда тумышы белән Табанлы Күл авылыннан булган Кадыйров Әмирҗан мөгаллимлек итә. 1930 елдан укулар латин графикасына күчерелә. Беренче укытучыбыз күрше Теләнче ( хәзерге Октябрь ) авылыннан Шәрипов Әмирҗан булды. 1 нче сыйныфта 16 бала укыдык. Шуларның 8 е малай, 8 е кыз бала идек.

Урта мәктәп итеп үзгәртелгәч, яшьләр тирә-як авыллардан да килеп укый башладылар. Мәсәлән, 1941 нче елның 15 нче июлендә 10 нчы классны тәмамлап, аттестат алучылар арасында Симәк, Мари-Буләр, Калинин (хәзерге Актаныш) районының Яхшый, Наратлы авылларыннан, Әмәкәй, Сөякәй, Әндереш, Дусай, Башкортстанның Бакалы районы Яңа Әмәкәй, Яңа Әлмәт, Яңа Әгъбәс, күрше Иске Карамалы, Түреш авылы егетләре һәм кызлары да бар иде.

Өс-баш киеме күпчелек балада сарык тиресеннән тегелгән ак тун, туладан эшләнгән чикмән, киндер күлмәк һәм ак эшләпә иде. Аякка чабата, ыштыр яки тула оек киеп йөрдек.

Авылда колхозлашу башлангач, җидееллык колхоз яшьләре мәктәбе (ШКМ) ачыла. Аңа якын-тирә авыллардан да килеп укыйлар.

1930-1931 нче уку елында хәзерге Октябрь авылыннан күчеп килгән Шәрипов Әмиржан мәктәптә мөдирлек итә. Мәктәпнең үз территориясендә байлардан тартып алынган 0,5 га күләмендә яшелчә бакчасы була. Анда бәрәңге, аш чөгендере, кишер,кәбестә, суган, кыяр, кавын, көнбагыш кебек культуралардан укучылар көче белән мул уңыш устерелә.Алынган уңыш укучыларга кайнар аш өчен файдаланыла.

ШКМ ачылу белән, культура революциясе башлана:хатын-кызларны 45 яшькә, ирләрне 55 яшькә кадәр укырга һәм язарга өйрәтү өчен, кичке мәктәп оештырыла.Авыл Советы, укытучылар җитәкчелегендә грамоталы кешеләрдән культармеецлар сайлап алына һәм укыту башланып китә. Культармеецлар булып

Исламов Фәхерлеислам, Вәлиева Мәгъруфзада, Тимерханов Мирмөҗәһидәннәр эшлиләр. Халык кыска вакыт эчендә укырга һәм язарга өйрәнә.

1930-1934 нче елларда мәктәптә укытучылар булып Шәрипов Әмирҗан, Әхмәтҗанов Галимҗан, Ибраһимов Миргалим, Зарипов, Әгъләмов Миңнулла, Кирамов, Гафурова Шәмсияләр эшли.

1935 нче елда, үз бинасына укучылар сыеша алмагач, уку колхоз карамагындагы җәмәгать биналарында дәвам иттерелә.

Хуҗалык ирешкән уңышлардан канатланып, куңеле тагын да үсеп киткән колхоз рәисенең ( Миңнехан Гайров) башына авылда урта мәктәп салдыру уе керә. Чаллы шәһәре янындагы урманнан озын ат арбалары белән мәктәпнең беренче ниргәләре кайтарыла башлый. Атлар белән 120 чакрым арадан агач ташу колхозга бик кыйммәткә төшә, әлбәттә. 1935 нче елның җәендә урта мәктәп бинасына нигез салына. Дәүләт тарафыннан күрсәтелгән гаять зур ярдәм белән бу 2 катлы бина 1938 нче елның 1 нче сентябрендә файдалануга тапшырыла һәм элекке ТБУМ (тулы булмаган урта мәктәп) урынына Күбәктә беренче мәртәбә урта мәктәп ачыла.

Шул елны, урын җитмәү сәбәпле, 5-7 нче сыйныф укучылары өчен колхоз ишек алдындагы столярлык мастерское, җәй көне балалар бакчасы һәм колхоз клубы биналары файдаланылды. Мәктәпкә Кубәк, Иске һәм Яңа Карамалы, Түреш авылларыннан килеп укыдылар. Озын тәнәфестә кайнар аш та оештырылды. 1939 нчы елдан яңа төзелгән ике катлы агач бинада инде 8 нче сыйныф та ачылды. Ләкин анда белем алу өчен һәр укучы елына 150 сум акча түләргә тиеш иде. Купчелек баланың әти-әнисе ул кадәр акча түли алмагач, мәктәпнен ташларга мәҗбүр булдылар. Мин дә, этигә 3 көн ялынгач кына, 8 нче сыйныфта укырга рөхсәт алдым. Инде 9-10 нчы сыйныфларда укыр өчен, җәй көне каникул вакытында, яр буена куыш ясап, кирпеч сугарга, көз көне, шуны сатып, акча юнәтергә туры килде.

Кубәк урта мәктәбе 1938-1941 нче елларда 1 нче мәртәбә чыгарылыш бирә. Ул вакытта мәктәп директоры булып Барыев Шәех ага эшли. Укытучылар Феклин Х.Н., Сөләйманов М.К., Шадрин К.Л., Шадрина А.К., Никифоров, Тимофеев, Спиридонов, Тукмачев, Гыймадов, Гыймадова, Вагыйзов, Ахунов, Абдуллин, Абдуллина, Гыйлаҗин (завуч), Галиева Н., Гарифуллина, Галиев, Шаһидуллин, Усманова, Дәминова, Мозаффаров, Акчурина, Кащиевлар укучыларга тирән белем бирергә тырыштылар.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Күбәк урта мәктәбендә укырга яшь егетләр калмый, ул яңадан ТБУМ га әверелә.

Сугыш елларында мәктәпнең материаль базасы бик нык ярлылана. Ике катлы бинаның аскы катындагы 5-6 бүлмәсе генә файдаланырлык була. Укучылар өчен дәреслекләр, уку әсбатлары, күрсәтмә материаллар җитешми.

1948-1951 нче елларда тузган мәктәп бинасына ремонт башлана. Югары каттагы бүлмә тәрәзәләренә пыяла куела, мичләр чыгарыла, аскы катның черегән бүрәнәләре имән бүрәнәләр белән алыштырыла. Мәктәпнең агач һәм яшелчә бакчасы булдырыла. Материаль һәм рухи базасы урта белем бирү дәрәҗәсенә җитә.

Урта мәктәп итеп үзгәртелгәч, яшьләр тирә-як авыллардан да илеп укый башладылар.

1951-1952нчы уку елында мәктәп районда икенче урта мәктәп итеп оештырыла. 1953-1954нчы уку елында сугыштан соң беренче мәртәбә мәктәпне 49 укучы тәмамлый. Укучылар Яңа Усы, Карл Либнехт, Яңа Сәфәр, Баек, Дусай, Түреш, Әмәкәй, Сөякәй, Октябрь, Әндереш, Мари Бүләр, Башкортстанның Үмер, Яңа Әгъбәс, Яңа Әмәкәй, Чуракай, Яңа Әлмәт авылларыннан да килеп укыйлар. Аерым елларда чыгарылыш класс укучыларының 100-104кә кадәр җиткәнен хәтерлим. Мәктәптә укучылар саны 600гә якынлашкан еллар булды.

Мәктәп бинасы тузды. Түбәсеннән яңгыр үтә башлады. Директор булып Мирза Мәйлүнов эшләгән вакытта Уфадан калай кайтартып(бү эш Гайров Рифкатькә йөкләнде), түбә яптырылды. Ишегалды койма белән әйләндереп алынды. Алма, чия, карлыган, кура җиләге, крыжовник кебек җиләк-җимеш үстерерлек тәҗрибә бакчасы булдырылды. Физика, химия, тарих, география фәннәрен практик тормыш белән бәйләү буенча киң мөмкинлекләр ачылды. Мәктәп көндезге вакытта 2 смена, ә кичке 6дан 10га кадәр кичке мәктәп функциясен дә башкарды.

1949 нчы елда Иске Карамалы авыл советы утырышы беркетмәләреннән кайбер өзекләр:

“Күбәк 7 еллык мәктәбенә капиталь ремонт үткәрү өчен  һәр колхоздан берәр плотник, барсы 4 кешенең мәктәп карамагына договор төзеп бирергә һәм тәрәзәләргә пыяла салу өчен  “Кызыл сабанчы” колхозыннан 1 кеше билгеләргә”.

Июнь, 1949.

Күбәк 7 еллык мәктәбе директоры Миңнулла Әгъләмов чыгышыннан: “Мәктәп буенча беренче чиректә 45 бала өлгермәде. Укытучылар Вәлиева, Петрова, Салихов, Әминов, Крымов, Исхакова һәм Хәсәноваларның эше мактауга лаек...”

Ноябрь, 1949.

“Күбәк уку йортына авыл Советының практик ярдәмен көчәйтергә һәм бер гармун, бер домино, бер шашка, мебельләр һәм 1 унлы лампа алып бирергә”.

Апрель, 1949.

“Укый-яза белмәүче гражданнарны укыту эшен 1951 нче елның 29 нчы гыйнвареннан да соңга калмыйча башлап җибәрергә. Бу эшне Күбәк авыл авылында мәктәп директоры Юнысов, депутатлар Бәдертдинов, Нәбиев, мәктәп завучы Вәлиевләргә йөкләргә һәм занятиеләрнең өзелми баруына ирешергә”.

Гыйнвар, 1950.

Авыл Советы сессияләрендә керосин юклыгы, күргәзмә материалның аз булуы, укыту өчен сыйныф бүлмәләренең җитешмәве тәнкыйтләнә. Бу чорда укытучылар өчен фатирларга мохтаҗлык та берничә мәртәбә телгә алына.

1951-1956 нчы елларда эшләгән укытучылар: Мәйлүнов М. (директор), Крымова Ә., Вәлиев С., Абдрәхимова А., Исхакова С., Зиннурова Ә., Миңсафин И., Гыйльманов А., Гыйльманова А., Әгъләмов М., Вәлиева Ә., Сәйфетдинов З., Усманова Р., Гайров Р., Шәвәлиева Н., Фәрхетдинов Х., Вәлиев З., Зарипов Р., Галимова Т., Миңнуллина Б., Нургаязова Җ.

Өлгергәнлек аттестаты алып чыктылар:

1953-1954 нче уку елында – 49 укучы;

1954-1955нче уку елында – 37укучы;

1955-1956нче уку елында – 51укучы;

1956-1957 нче уку елында – 28укучы.

“Укыту-тәрбия эшенең тормыштан аерылганлыгын бетерү һәм укучыларга политехник белем бирү өчен, мәктәп дирекциясе шактый эшләр башкарды. Мәктәпнең мастерское, тракторы, комбайны, автомашинасы, төрле тагылма алу хуҗалыгы машиналары булдырылды. Укучылардан махсус производство бригадасы оештырылды. Бригада членнары “ Алга” колхозына 927 баш чебеш үстереп бирделәр. Тәҗрибә участокларында кукуруздан һәм азык чөгендереннән мул уңыш

үстерделәр. Мәсәлән, азык чөгендеренең уңышы гектардан уртача 380 центнер булды.

Бакчачылыктан да югары уңыш алына башлады (“Күбәк урта мәктәбе тарихы” альбомыннан,М. Әгъләмов).

1975 нче елда Куйбышев исемендәге колхозның Күбәк товарлыклы –сөтчелек фермасы мөдире Татарстан АССР Верховны Советы депутаты Ганиева Канитә Хәмәевнаның Мөсли районы партия конференциясендә ясаган чыгышыннан:

“Мин үзем Күбәк авылыннан. Анда тирә-юньдәге 10-15 авылдан килеп укучыларны да керттем, 500 бала укый торган урта мәктәп бар. Ләкин биредә киләчәк буынга хәзерге таләпләргә туры килә торган тиешле тәрбия бирерлек бернини шарталар да юк. Мәктәп ярым авария хәленә килгән. 3 бинага урнашкан. Класслар кысан, 2 сменадаалып барыла. Класс-кабинетлар оештыру, түгәрәкләр һәм башка класстан тыш эшләр үткәрү бик кыен. Үзебезнең сайлаучыларыбыз исеменнән 1975 нче ел планына Иске Карамалы Авыл Советына караган Күбәк авылына Татарстан АССР мәгариф министырлыгының татнефтестройдагы подряд лимиты хисабына урта мәктәп төзүне кертүне үтенәм. Чәнки мәктәп үзәге урнашкан Куйбышев исемендәге колхозда берничә ел рәттән, һава шартлары кырыс килү сәбәпле, акча керү планнары үтәлми”.

1979 нчы елда Район Советы рәисе Гариф Хафизов, Район мәгариф бүлеге мөдире Зәйнагетдин Вәлиев эшләгән вакытта 386 укучының исәпләнгән ике катлы яңа бина сафка бастырылды. Мәктәпне Бөгелмәдәге ПМК (начальнигы Сорокин) бер җәй эчендә төзеде. 1979 нчы елның 22 нче октяберендә аны ачу тантанасы булды. Мәктәп өчен кирәк булган бөтен җиһазны миңа Казаннан ташырга туры килде.

**(*Сәйдел Вәлиев, Мөҗәһит Әхмәтҗановның “Күбәгем – туган төбәгем” китабыннан алынды*)**




Мәктәпнең хәзерге бинасы 1979 нчы елда 386 укучыга төзелә. Гомуми күләме 2290 кв.м.. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы башкарма комитетының Карары (№284, 04.06.2012 нче ел) нигезендә Яңа Карамалы башлангыч белем бирү мәктәбе Күбәк урта мәктәбенең филиалы итеп үзгәртелә. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы башкарма комитетының Карары (№735, 24.12.2018 нче ел) нигезендә Яңа Карамалы башлангыч белем бирү мәктәбе ябыла. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы башкарма комитетының Карары (№115, 23.03.2016 нчы ел) нигезендә Октябрь башлангыч белем бирү мәктәбе Күбәк урта мәктәбенең филиалы итеп ачыла. Бүгенге көндә 1, 2, 4 нче сыйныфларда 4 укучы белем ала, югары белемле 2 укытучы укыта. Компьютер, ноутбук, спорт җиһазлары бар. Бинада балалар бакчасы да урнашкан.

2020-2021 нче уку елында мәктәптә 116 укучы белем һәм тәрбия ала. Укытучылар - 24. 1 нче сыйныфка 7 укучы кабул ителде һәм 1-10 нчы сыйныф укучылары яңа белем бирү стандартлары буенча белем ала. 11 нче сыйныфта 3, 9 нчы сыйныфта 15 укучы укый. Укыту татар һәм рус телләрендә алып барыла.